Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге Советы

Шәле авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

10 сентябрь, 2026 ел № 11

Шәле авылы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге
Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Шәле авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 15 номерлы карары белән (2017 елның 13 декабрендәге 30 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 12 номерлы, 2019 елның 7 октябрендәге 52 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 57 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 64 номерлы, 2024 елның 15 мартындагы 2 номерлы карары белән), Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокукларына ия булучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны үткәрүне оештыручыны - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 25 сентябереннән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ... ПЕСТРЕЧИНСКОГО ... СОВЕТ ... СКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1633000962